***Сибгаева Ф.Р.***

***Казан ш.***

# ФРАЗЕОЛОГИК БЕРӘМЛЕКЛӘРНЕ РУС ТЕЛЕННӘН ТАТАР ТЕЛЕНӘ ТӘРҖЕМӘ ИТҮ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

Рус теленнән татар теленә тәрҗемә итүнең тарихы безнең ерак бабаларыбыз борынгы болгарлар һәм кыпчакларның руслар белән дустанә мөнәсәбәт урнаштырган заманнардан ук башлана. Бу ике халык арасындагы бәйләнештә тәрҗемә кулланылмый калмаган. Шуннан чыгып, рус теленнән татар теленә тәрҗемәнең тарихы бик еraклардан ук башланган дип әйтергә кирәк.

Тәрҗемәнең төп принциплары барлык телләр, тәрҗемә ителә торган барлык материал өчен уртак. Иң мөһиме – төп нөсхәнең эчтәлеге һәм формасы берлеген мөмкин кадәр тулырак саклау бурыч итеп куела. Тәрҗемә теориясе теләсә нинди теоретик модель кебек, сурәтләнә торган әйбернең яисә процессның якынча характерлы билгеләрен күрсәтә. Күренекле рус галиме Л.С. Бархударов билгеләвенчә, тәрҗемәдә төп текст һәм тәрҗемә ителә торган текст бар. Ул тәрҗемәгә түбәндәге билгеләмәне бирә: “Переводом называется процесс преобразования речевого произведения на одном языке в речевое произведение на другом языке при сохранении неизменного плана содержания, то есть значения” (1,11). Димәк, галимнәр фразеологик әйтелмәләрне турыдан-туры тәрҗемә итү мөмкин түгел дип саныйлар, ләкин соңгы елларда тел белемендә “тәрҗемә ителми торган” фразеологизмнарны тәрҗемә итү мәсьәләсе актуальләшеп китте.

Фразеологизмнарның бер телдән икенче телгә үтеп керүе берьяклы гына процесс түгел: ул рус теленнән татар теленә таба гына түгел, бәлки татар теленнән рус теленә таба да бара. Татар әдәбиятының күп кенә әсәрләрен русчага тәрҗемә итү нәтиҗәсендә, татар теле фразеологизмнарының күбесе рус теленә калькалаштырыла. Бу тәрҗемә теориясендәге принципка нигезләнә: оригинал фразеологизмнар бердәй мәгънә һәм образлылыкны, сурәтлелек,

җыйнаклыкны тел нормасын бозмыйча сакларга мөмкин булганда, тәрҗемәдә бирелергә, ягъни төп мәгънәле тәңгәллекләре белән тәрҗемә ителергә тиеш. Бу принцип русчадан татарчага һәм татарчадан русчага тәрҗемә иткәндә кулланыла. Рус классик әсәрләренең татарча тәрҗемәләрендә фразеологик берәмлекләр лексик-семантик һәм әдәби максатны да күздә тотып файдаланыла.

В.Виноградов лексик фразеологизмнарны тәрҗемә итүнең өч төрле юлын күрсәтә:

1. Фразеологик эквивалент - икенче телдә шундый ук фразеологик әйтелмәне табу. Биредә оригиналдагы кебек шул ук мәгънә, стильара билгеләр үзгәрми һәм эчке форма төгәллеге саклана.

2. Тулы булмаган фразеологик эквивалент - һәрбер мәгънәдә дә тулы булмаган фразеологизм белән тәрҗемә итү. Ягъни телдә икенче мәгънәсе булу шарт булып тора, ләкин бу юл телдә сирәк күренеш булып тора.

3. Бер сүздән торган өлешчә эквивалент (однословные частичные эквиваленты) (2; 94-99).

Кайбер галимнәр, чагыштырма эквивалент һәм индивидуаль эквивалентны да аерып күрсәтү ягында. Чагыштырма эквивалент юлны кулланып тәрҗемә иткән вакытта морфологик һәм синтаксик яктан үзгәрешләр барлыкка килә. Индивидуаль эквивалент булганда тәрҗемәче сүзне яисә тәгъбирне үзе уйлап чыгара, ләкин бу телдә уелып калмаска мөмкин.

Фразеологизмны фразеологик әйтелмә белән тәрҗемә итүдә фразеологик эквивалент әһәмиятле урын алып тора, чөнки тәрҗемәдә фразеологизмны шул телдәге фразеологик әйтелмә белән күрсәтү тәрҗемәчедән телнең үзенчәлекләрен белүне һәм сүзлек белән оста файдалануны таләп итә. Тәрҗемә әсәрләрдә фразеологик эквивалентлар түбәндәгечә кулланылыш таба:

*Набрать в рот воды* - *авызга су кабу:*

- *Чего ж воды в рот набрали,* - *досадуя, спросил Иван Алеексеевич (М. Шолохов «Тихий Дон»).*

- *Ник авызыгызга су каптыгыз?* - *дип, ачуы килебрәк сорады Иван Алексеевич (М. Шолохов «Тын Дон»).*

*Набрать в рот воды* - хранить упорное молчание, ничего не говорить. ФСРЯ - 260 с.

*Авызга су кабу* - сораганда җавап бирмәү, дәшми утыру (4; 96).

Лишний рот - Артык кашык:

*Тяжело быть лишним ртом в семье (Куприн «Гранатовый браслет».*

*Аннары гаиләдә артык кашык булып яшәү дә кыен (Куприн «Гранат кашлы беләзек»).*

*Лишний рот* - человек, который обременяет других, в тягость другим как едок (3; 392).

*Артык кашык* - гаиләдә үзенекеләр өстенә кардәш-ыру яки башка кемне асрауга карата (4; 30).

*Между небом и землёй* - 1. Без жилья, без крова, без пристанища (жить). 2. В неопределенном состоянии (быть, находиться) (3; 272).

Югарыдагы мисаллардан күренгәнчә, фразеологик әйтелмәне фразеологизмны тулы эквиваленты белән тәрҗемә итү рус классик әсәрләренең тәрҗемәләрендә еш кулланылган. Әлеге күренеш тәрҗемәчеләрнең сурәтләү һәм тел осталыкларын дәлилли.

Тулы булмаган фразеологик эквивалент. Әлеге очракта фразеологизм тулы, ләкин һәрбер мәгънәдә туры килми. Мәсәлән, телдә икенче мәгънәсе дә булырга мөмкин.

Выбивая дробь зубами - Теше тешкә тими.

- *Что-то Михаил? Что такое? - лепетал он, выбивая дробь зубами. (М.Шолохов «Тихий Дон»).*

- *Нәрсә бар, Михаил? Ни булды? — дип сөйләнде ул, теше-тешкә тими калтыранып (М.Шолохов «Тын Дон»).*

Теше тешкә тими - 1. Бик каты өшеп-туңып, тешләрнең бер-берсенә тигәнче үзлегеннән сикереп тиешүләре. 2.Чәйнәп тә тормый кызу-кызу ашау (3;200).

Индивидуаль эквивалент белән тәрҗемә иткәндә тәрҗемәче үзе уйлап чыгара. Әлеге очрак тәрҗемәчеләр тарафыннан актив кулланылмый.

Дать тягу - аякны авызга кабу.

*Теперь драла, иначе говоря, я даю тягу, или, как выражаются при дворе, удираю. (М.Шолохов «Тихий Дон») — Аягымны авызыма кабам яки таям.*

Шулай итеп, фразеологизмны фразеологизм белән тәрҗемә итү рус классик әсәрләренең тәрҗемәләрендә еш кулланыла. Әлеге күренеш, беренчедән, тәрҗемә әсәренең тулылыгын, аһәңлелеген күрсәтсә, икенчедән, тәрҗемәчеләрнең тел осталыкларын билгели.

Лексик берәмлек аша тәрҗемә итүгә тәрҗемәчеләр фразеологик әйтелмә белән тәрҗемә итеп булмаган очракта гына кулланалар. Мондый тәрҗемәдә күбесенчә образлылык, экспрессивлык, мәгънә төсмере үзгәрә, шуңа күрә тәрҗемәчеләр лексик берәмлек аша тәрҗемә итүне соңгы очракта гына кулланалар.

Фразеологизмны фразеологизм белән тәрҗемә итмәү очракларының 3 төре бар: лексик тәрҗемә итү; калькалаштыру; тәрҗемә-сурәтләү.

Кайбер галимнәр (М.М.Копыленко, Я.И.Рецкер) контекстуаль һәм сайлап тәрҗемә итү (выборочный) төрләрен дә аералар.

1. *Лексик тәрҗемә итүдә* беренче сүз фразеологизм, икенчесе - сүз, ләкин алар фразеологизмга якын булырга тиеш. Без тикшергән тәрҗемәләрдә әлеге очракка мисаллар юк диярлек:

*И чтение это производило в нем всегда удивительное волнение желчи. (Л. Толстой «Анна Каренина»)*

*һәм бу уку аның саруын гаҗәп дәрәҗәдә кайната. (Л. Толстой «Анна Каренина»)*

Югарыдагы мисалдан күренгәнчә, төрле телләрдәге фразеологизмнар, бер үк мәгънә белдерсәләр дә, составлары ягыннан бер-берсенә туры килмәскә мөмкиннәр. Төзелешендә һәм мәгънәсендә теге яки бу телнең кабатланмас үзенчәлекләрен чагылдырган фразеологик берәмлекләрне тел белемендә идиомалар дип атыйлар. Лексик тәрҗемә итүне башкача атаганда идиома дияргә дә мөмкин.

2. *Калькалаштыру,* ягъни сүзгә-сүз тәрҗемә. Фразеологизмнар,

кагыйдә буларак, телнең үз байлыгы нигезендә барлыкка киләләр. Ләкин халыклар, телләр арасында бәйләнеш, тәрҗемә процессында фразеологизмнар да бер телдән икенче телгә күчәргә яисә калькалаштырылырга мөмкин. Мәсәлән, татар теленә рус теленнән мондый фразеологизмнар кергән: *дамоклов меч - домокл кылычы, делать из мухи слона — чебеннән фил ясау.*

Рус классик язучыларының тәрҗемәләрендә калькалаштыру очрагына мисаллар күп түгел:

Под рукой (в руках) - Кул астында.

*Мы должны иметь под рукой часть резервов Третьей дивизии для того, чтобы в случае прорыва нам было чем заслонить его. (М.Шолохов «Тихий Дон»)*

*Фронт өзелгән очракта аны тотып калыр өчен, өченче дивизия резервының бер өлеше безнең кул астында булырга тиеш. (М.Шолохов «Тын Дон»)*

*В руках* - создаваемое, выполняемое или созданное, выполненное кем-либо (4; 398).

*Кул астында* - 1. Идарәсендә, карамагында. 2. Якында, монда гына (3; 154).

Пожирать глазами - Күз белән ашау.

*Правда, что тон ее был такой же, как и тон Сафо; так же, как и за Сафо, за ней ходили, как пришитые, и пожирали ее глазами. (Л.Толстой «Анна Каренина»)*

*Дөрес, аның сөйләшү тоны Сафоныкы шикелле үк; Сафо артыннан 2 ухажер йөрсә,... бер дә калмыйча йөриләр, күзләре белән аны ашардай булып торалар. (Л. Толстой «Анна Каренина»)*

*Пожирать глазами* - пристально, неотрывно или подобострасно смотреть на кого-либо или на что-либо (3; 307).

*Күзе белән ашау* - кешегә бик каты әсәренеп, йотылып карау, яратып яки кешене йота-йота карау (4; 165).

3. *Тәрҗемә-сурәтләү.* Фразеологизмның үзен түгел, ә аерым сүзләрен

генә тәрҗемә очраклары белән тәрҗемә итү итә. Телдәге фразеологик әйтелмәнең турысын табу кыен, шуңа күрә әйтелмәнең лексик мәгънәсенә якын торган сүзләр белән белдерү автор өчен дә, укучылар өчен уңайлы форма булып тора. Мәсәлән:

Отводить душу - җан рәхәтләнү.

-*Не без того.*

-*Душу отводили. (Л. Толстой «Анна Каренина»)*

-*Ансын булмый инде.*

-*Җаныгыз рәхәтләнгәндер. (Л. Толстой «Анна Каренина»)*

*Отводить душу* - находить для себя утешение, успокоение, разрядку в чем-либо, обычно в каком - либо занятии, дела, разговоре и т.п.

*Җан рәхәтләнү* төзелмәсе сүзлекләрдә теркәлмәгән.

Кайбер очракларда тәрҗемәчеләр аерым сүзне дә фразеологик берәмлек буларак тәрҗемә итәләр. Мәсәлән, Л.Толстойда, М.Шолоховта *отказался*, М.Купринның «Олеся» хикәясендә *застыдился* сүзләре татарчага *баш тарту* фразеологизмы белән бирелә:

Отказался, застыдился - баш тарту.

*Урядник для виду застыдился. (А.Куприн «Олеся») - Урядник юри генә баш тарткан булды.*

*Отдай этому мужику; он не откажется. (Л.Толстой «Анна Каренина»)* - *Менә шушы мужикка бир; ул баш тартмас.*

*Коршунов наотрез отказался платить, прижимая полевевшую деньгу. — Коршунов, бәясе төшкән акчасын жәлләп, түләүдән бөтенләй баш тартты. (М.Шолохов «Тын Дон»)*

Прислушаться, помянуть - колак салу.

Купринның «Олеся» әсәрендә *прислушиваясь*, «Гранат кашлы беләзек» хикәясендә *помяни* сүзләре татарчага *колак салу* дип тәрҗемә ителә:

*Я еще долго глядел в темноту, прислушиваясь к частым, удалявшимся от меня шагам. (А.Куприн «Олеся») — Мин аның ераклаша барган аяк тавышына колак салып, әле бик озак шул караңгылыкка күзләремне текәп торам.*

*Помяни мое слово, что лет через тридцать женщины займут в мире неслыханную власть. (А.Куприн «Гранатовый браслет») - Мин әйткән сүзләрне колагыңа салып куй: 20-30 елдан соң хатын-кызлар дөньядагы моңарчы күрелмәгән хакимияткә ирешәчәкләр. (А.Куприн «Гранат кашлы беләзек»)*

Шулай итеп мисаллардан күренгәнчә, сүзне фразеологизм белән тәрҗемә итү һәм контекстка, һәм тәрҗемәченең үткен теллелегенә, сүз сурәтләү осталагына бәйле. Бүгенге көндә фразеологизмнарны дөрес итеп тәрҗемә итү мәсьәләсе һәр тел өчен хас, актуаль булып кала бирә.

**Әдәбият**


1. Бархударов Л.С. Язык и перевод. – М.: Международные отношения, 1975. – 239 с.
2. Виноградов В.С. Введение в переводоведение (общие и лексические вопросы). - М: Издательство института общего среднего образования РАО, 2001 – 246 с.
3. Татар теленең фразеологик сүзлеге / Төз. Н. Исәнбәт. - Яр Чаллы: Идел йорт, 2000. – 236 б.
4. Фразеологический словарь русского языка / Под ред. А.И. Молоткова. – М.: Сов. Энциклопедия, 1967. – 543 с.
5. Юсупов Р.А. Лексико-фразеологические средства русского и татарского языков. – Казан, 2005. – 225 б.